БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» март 2020 ел № 123

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 27 декабрендәге 362 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча Балтач яшьләр (мәктәп) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 4 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясенең төп нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында, «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмә исемендә һәм алга таба текст буенча «мәктәп» сүзен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча Балтач яшьләр формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директорына Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 10 номерлы районара салым инспекциясендә Татарстан Республикасы Контроль-хисап палатасы Нигезләмәсенә үзгәрешләрне һәм юридик затларның бердәм дәүләт реестрында башка үзгәрешләрне теркәгәндә, әлеге максатларда кирәкле гаризаларга һәм башка документларга имза салу, законнарда каралган тәртиптә һәм вакытларда башка гамәлләр кылу һәм рәсмиләштерүләр башкару вәкаләтләрен дә биреп, мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясау өчен вәкаләт бирергә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан

Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов